**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 октябрендәге 4193 номерлы карары**

**Татарстан урамы һәм Габдулла Тукай урамы киселешендә (Сара Садыйкова скверы) территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьяларына, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану хакында»гы федераль законның 8 статьясына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 19 августындагы 3401 номерлы «Татарстан урамы һәм Габдулла Тукай урамы киселешендәге территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган «Центр» территориясен планлаштыру проектына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә Татарстан урамы һәм Габдулла Тукай урамы киселешендәге (Сара Садыйкова скверы) территорияне ызанлау проектын расларга;

1.2. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль

хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга;

1.3. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.4. әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә:

2.1.1. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлекләренә карата дәүләт кадастр исәбе алып бару һәм муниципаль милек хокукын теркәү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә;

2.1.2. әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә алганнан соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә адреслы номерлар бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен җир кишәрлегенең кадастр номеры турында мәгълүматны тапшырырга;

2.2. җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда:

2.2.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмаларның аларга тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

2.2.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

2.2.3. Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы, җирләрдән файдалануның махсус режимнары исемлегенә кертелгән XV – XX гасырның беренче чирегенә караган «Казан Кремле Ансамбле» (Татарстан Республикасы (Татарстан) федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен раслау турында»гы әмере белән расланган «Казан Кремле Ансамбле», XV – XX гасырларның беренче чирегенә караган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларыннан

файдалану режимнарын һәм таләпләрен һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне үтәүргә;

2.2.4. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы әмере белән расланган Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне үтәргә;

2.2.5. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 953-п номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясен файдалануның характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм хуҗалык эшчәнлегенә таләпләр, Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә проектлау һәм төзү турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән расланган «Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә урнашкан «Казан шәһәренең XI-XVIII гасырлардагы тарихи үзәгенең мәдәни катламы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектына карата чикләүләрне үтәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 4 октябрендәге
4193 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан урамы һәм Габдулла Тукай урамы киселешендә (Сара Садыйкова скверы) территорияне ызанлау проекты**

Татарстан урамы һәм Габдулла Тукай урамы киселешендә (Сара Садыйкова скверы) территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән территорияне ызанлау проекты турындагы нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап).

III. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап).

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып торалар һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Ызанлау проекты рөхсәт ителгән файдалану төре булган җир кишәрлекләрен булдыру – территорияне төзекләндерү максатыннан әзерләнде.

Ызанлау проекты ике этапта эшләнә.

Беренче этапта шартлы билгеләнеше :ЗУ1 булган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә муниципаль милектә булган 16:50:011711:34 кадастр номерлы җир кишәрлеген һәм беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен – дарухanә бинасы өчен билгеләп, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңача бүлү юлы белән формалаштырыла.

:ЗУ1 ясау Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 мартындагы 717 номерлы «Татарстан урамы һәм Г.Тукай урамы киселешендәге торак булмаган бинаны (даруханәне) сүтү эшләрен башкару турында»гы карары нигезендә кадастр номеры 16:50:011711:42 булган капиталь төзелеш объектын сүткән очракта мөмкин.

Шартлы билгесе :ЗУ2 булган җир кишәрлеге, рөхсәт ителгән файдалану төрен – территорияне төзекләндерү билгеләп, чикләнмәгән дәүләт милке җирләреннән төзелә.

Шартлы билгесе :ЗУ3 булган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә муниципаль милектә булган 16:50:011711:27 кадастр номерлы җир кишәрлеген һәм беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен – сәүдә павильоны өчен билгеләп, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңача бүлү юлы белән формалаштырыла.

Шартлы билгесе :ЗУ4 булган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен – юл өчен (16 номерлы төр) билгеләп, муниципаль милектә булган 16:50:000000:19289 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлеген саклап калып бүлү юлы белән формалаштырыла.

Шартлы билгесе :ЗУ5 булган җир кишәрлеге рөхсәт ителгән файдалану төрен – территорияне төзекләндерү билгеләп, чикләнмәгән дәүләт милке җирләреннән төзелә.

Шартлы билгеләнеше :ЗУ 5 җир кишәрлеге – :ЗУ5(1), :ЗУ5(2), :ЗУ5(3), :ЗУ5(4) контурларыннан торган күп контурлы җир кишәрлеге.

1 таблица

| **Җир кишәрлегенең шартлы номеры** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Беренчел җир кишәрлекләре, аларның кадастр номерлары** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | Даруханә бинасы | 16:50:011711:34, чикләнмәгән дәүләт милке җирләре | 1391 |
| :ЗУ2 | Территорияне төзекләндерү | чикләнмәгән дәүләт милке җирләре | 143 |
| :ЗУ3 | Сәүдә павильоны | 16:50:011711:27, чикләнмәгән дәүләт милке җирләре | 182 |
| :ЗУ4 | Юл (16 номерлы төре) | 16:50:000000:19289 | 743 |
| :ЗУ5 | Территорияне төзекләндерү | чикләнмәгән дәүләт милке җирләре | 115 |

Беренче этаптагы кадастр эшләрен уздырганнан соң шартлы билгеләре :ЗУ1 һәм :ЗУ3 булган ясала торган җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен территорияне төзекләндерү – рөхсәт ителгән файдалану төренә алмаштыруны күздә тотарга кирәк.

Икенче этапта шартлы билгеләре :ЗУ4, :ЗУ5 булган җир кишәрлекләрен, муниципаль милектәге 16:50:011711:37 кадастр номерлы җир кишәрлеген һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төрен – территорияне төзекләндерү билгеләп, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү юлы белән шартлы билгесе :ЗУ6 булган җир кишәрлеге ясала.

2 таблица

| **Җир кишәрлегенең шартлы номеры** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Беренчел җир кишәрлекләре, аларның кадастр номерлары** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ6 | Территорияне төзекләндерү | :ЗУ4, :ЗУ5, 16:50:011711:37, чикләнмәгән дәүләт милке җирләре | 975 |

Барлыкка килә торган җир кишәрлекләре Ц территориаль зонасында – шәһәр үзәгенең катнаш төзелеш зонасында урнашкан.

Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 24 статьясындагы 7 пункты (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә җир кишәрлекләрен һәм җирләрне яңадан бүлгәндә җир кишәрлекләренең минималь үлчәмнәре кулланылмый, даруханә бинасы һәм сәүдә павильоны өчен – рөхсәт ителгән файдалану төрләре булган җир кишәрлекләре өчен иң максималь чик үлчәмнәре билгеләнмәгән, юл өчен (16 номерлы төр) рөхсәт ителгән файдалану төре өчен җир кишәрлекләренең иң минималь һәм иң максималь чик үлчәмнәре билгеләнмәгән.

Кагыйдәләрнең 26 статьясы нигезендә әлеге территориаль зона өчен иң максималь һәм иң минималь чик үлчәмнәре билгеләнмәгән рөхсәт ителгән файдалану төрен – территорияне төзекләндерү билгеләргә мөмкин.

Җир кишәрлекләре түбәндегеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;


- эшләп килүче инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, файдаланучы оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы, җирләрдән файдалануның махсус режимнары исемлегенә кертелгән XV – XX гасырның беренче чирегенә караган «Казан Кремле Ансамбле» (Татарстан Республикасы (Татарстан) федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен раслау турында»гы әмере белән расланган «Казан Кремле Ансамбле», XV – XX гасырларның беренче чирегенә караган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларыннан файдалану режимнарын һәм таләпләрен һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне үтәүргә;

- Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы әмере белән расланган Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне үтәргә;


- Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 953-п номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясен файдалануның характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм хуҗалык эшчәнлегенә таләпләр, Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә проектлау һәм төзү турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән расланган «Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә урнашкан «Казан шәһәренең XI-XVIII гасырлардагы тарихи үзәгенең мәдәни катламы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектына карата чикләүләрне үтәргә.

## II. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап)




| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| | Гамәлдәге кызыл линияләр |
| | Ызанлау проекты чиге |
| | Ясала торган җир кишәрлегенең чиге |
| | Беренчел җир кишәрлегенең чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлеге чиге в |
| | Территориаль зона чиге |
| | Кадастр кварталы чиге |
| 16:50:011711 | Кадастр кварталы номеры |
| 16:50:000000:19289,<br>16:50:011711:27,<br>16:50:011711:34,<br>16:50:011711:37 | Беренчел җир кишәрлекләренең кадастр номерлары |
| •1 | Ызанлау проекты чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| •н1 | Ясала торган һәм төгәлләштерелә торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары номерлары |

# III. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап)




| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| | гамәлдәге кызыл линияләр |
| | ызанлау проекты чиге |
| | Ясала торган җир кишәрлегенең чиге |
| | Беренчел җир кишәрлегенең чиге |
| | Гамәлдәге җир кишәрлеге чиге |
| | Территориаль зона чиге |
| | Кадастр кварталы чиге |
| 16:50:011711 | Кадастр кварталы номеры |
| :ЗУ4, :ЗУ5, 16:50:011711:37 | Беренчел җир кишәрлекләренең шартлы һәм кадастр номерлары |
| •1 | Ызанлау проекты чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| •Н1 | Ясала торган һәм төгәлләштерелә торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары номерлары |